ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

___ 16.02.2024___ № 205 ____

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елга муниципаль берәмлек балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакының нормативларын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 2679 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елга муниципаль берәмлек балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 2679 номерлы карарын (29.09.2017 № 2451 карары редакциясендә).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин